**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы**
**КАРАРЫ**

Актүбә ш.т.п. №14 "24" апрель 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының 2012 елның 14 маендагы 15 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында
(27.02.2015 №3, 10.09.2015 №24, 13.04.2016 №4 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 30 октябрендәге 299-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 декабрендәге 455-ФЗ номерлы Федераль законнарны үтәү йөзеннән

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының 2012 елның 14 маендагы 15 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакындагы нигезләмәгә (27.02.2015 №3, 10.09.2015 №24, 13.04.2016 №4 карарлар редакциясендә) 1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«1.4. Гавами тыңлауларга мәҗбүри рәвештә түбәндәгеләр чыгарыла:

1) җирлек уставы проекты, шулай ук гамәлдәге Уставны әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында Уставка Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, конституция (устав) яки Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен төгәл кабатлау формасында үзгәрешләр кертелгән очраклардан тыш, гамәлдәге уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты;

2) җирлек бюджеты проекты һәм аның үтәлеше турында хисап;

3) җирлекнең социаль-икътисадый үсеш стратегиясе проекты;

4) җирлекне үзгәртеп кору турындагы сораулар, моңа тавыш бирү юлы белән яисә гражданнар җыеннарында белдерелгән җирлек халкының ризалыгын алу таләп ителә торган «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә җирлекне үзгәртеп кору турындагы мәсьәлә.

Генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияләрне чикләү проектлары, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, күрсәтелгән документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар, җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проектлары, рөхсәт ителгән чикнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турында карар проектлары буенча капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, җир участокларыннан һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен җирдән файдалану һәм төзелешнең расланган кагыйдәләре булмаганда мондый куллануның икенче төренә үзгәртү мәсьәләләренә ачык тыңлаулар үткәрү мәҗбүри түгел. Алар буенча җәмәгать фикер алышулары үткәрелергә мөмкин.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис Р.А. Галиева